ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**18.02.2019** **№ 192**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2018 - 2020 елларга Алабуга муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча муниципаль программаны раслау турында"гы 2017 елның 8 декабрендәге 1546 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль берәмлегендә хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау системасындагы чараларны гамәлгә ашырганда башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, хокук саклау органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген оештыруны камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2018-2020 елларга Алабуга муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча муниципаль программаны раслау турында"гы 2017 елның 8 декабрендәге 1546 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендәге "2018 - 2020 елларга” сүзләрен “2018 - 2021 елларга” сүзләренә алмаштырырга.

2. “2018 - 2021 елларга Алабуга муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау һәм җәмәгать тәртибен саклау буенча муниципаль программа”ны (алга таба – Программа) яңа редакциядә бәян итәргә.

3 Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин